ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 117-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары М.Һ. Галиев, Р.И. Мистахов, М.И. Фәлахов, Р.Г. Хөсәенов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 117-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2025 елның 29 октябре
№ 435-VII ДС

Проект

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
М.Һ. Галиев, Р.И. Мистахов,
М.И. Фәлахов, Р.Г. Хөсәенов
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» 2010 елның 2 августындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 8 – 9; 2012, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш); 2019, № 40 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 81 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасы инновация сәясәтенең максатларын, бурычларын һәм принципларын билгели, инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәме чараларын билгеләүгә һәм гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне, шул исәптән Татарстан Республикасында кече технологик компанияләргә дәүләт ярдәмен тормышка ашыру үзенчәлекләрен, җайга сала.»;

2) 2 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

«12) кече технологик компания – инновация технологияләреннән файдаланып продукция эшләү һәм (яисә) җитештерү (хезмәтләр күрсәтү, эшләр башкару) буенча «Россия Федерациясендә технологик компанияләрне үстерү турында» 2023 елның 4 августындагы 478-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән шартларга туры килә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы һәм кече технологик компанияләр реестрына аның хакында белешмәләр кертелгән Россия коммерциячел оешмасы.»;

б) 2 өлештә «Фән һәм дәүләт фәнни-техник сәясәте турында» 1996 елның 23 августындагы 127-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба – Федераль закон)» сүзләрен «Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында» сүзләренә алмаштырырга;

3) 14 статьяда:

а) исемдә «төп» сүзен төшереп калдырырга;

б) беренче абзацта «Дәүләт ярдәменә» сүзләрен «1. Дәүләт ярдәменә» сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Дәүләт ярдәменә дәгъва белдерә торган инновация проектларына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан башка таләпләр дә билгеләнергә мөмкин.»;

4) 15 статьяда:

а) 2 өлештә «әлеге Законда каралган таләпләргә» сүзләрен «әлеге Законның 14 статьясында каралган таләпләргә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә:

в) 1 пунктта «эшчәнлек төренең» сүзләреннән соң «Фән һәм дәүләт фәнни-техник сәясәте турында» 1996 елның 23 августындагы 127-ФЗ номерлы» сүзләрен өстәргә;

г) 2 пунктта «әлеге Законның 14 статьясы таләпләренә» сүзләрен «әлеге Законның 14 статьясында каралган таләпләргә» сүзләренә алмаштырырга;

5) 18 статьяның 1 өлешендәге җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) «Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән башка рәвешләрдә.»;

6) түбәндәге эчтәлекле $18^1$ статья өстәргә:

«$18^1$ статья. **Кече технологик компанияләргә дәүләт ярдәмен гамәлгә ашыру үзенчәлекләре**

1. Кече технологик компанияләргә дәүләт ярдәме Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, шулай ук мондый ярдәмне үзләре аша гамәлгә ашыру мөмкинлеге булган тиешле оешмалар тарафыннан «Россия Федерациясендә технологик компанияләрне үстерү турында» 2023 елның 4 августындагы 478-ФЗ номерлы Федераль законда һәм әлеге Законда каралган рәвешләрдә тормышка ашырыла.

2. Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән салымнар түләү буенча ташламалар бирү рәвешендәге һәм (яисә) финанс белән тәэмин итү рәвешендәге дәүләт ярдәменә дәгъва белдерә торган кече технологик компания үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырырга һәм салымнарны Татарстан Республикасы бюджетына түләргә тиеш.

3. Кече технологик компанияләргә Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән дәүләт ярдәмен гамәлгә ашыруның башка үзенчәлекләре дә билгеләнергә мөмкин.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты кече технологик компанияләрнең инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәмен гамәлгә ашыру принципларының бердәм системасын булдыруга һәм Россия Федерациясендә кече технологик компанияләрнең инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәме өлкәсендә төп төшенчәләрне һәм принципларны билгеләүгә юнәлдерелгән «Россия Федерациясендә технологик компанияләрне үстерү турында» 2023 елның 4 августындагы 478-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезләмәләрен үстерү йөзеннән эшләнде.

Аерым алганда, Федераль законның 4 статьясындагы 9 өлешендә Россия Федерациясе субъектлары законнары, Россия Федерациясе субъектларының иң югары башкарма органнары норматив хокукый актлары белән Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары акчалары исәбеннән кече технологик компанияләргә дәүләт ярдәмен гамәлгә ашыру үзенчәлекләре билгеләнергә мөмкин дип билгеләнә.

2025 елга Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасында (алга таба – Рәиснең Юлламасы) кече һәм урта эшкуарлыкның сыйфатлы үсешен тәэмин итү өчен гамәлдәге ярдәм чараларының нәтиҗәлелеген арттыру, бизнесның таләпләрен исәпкә алып яңа инструментлар эшләү зарурлыгы билгеләп үтелде. Аерым игътибарны таләп итүче тармаклар арасында кече технологик компанияләр дә әйтелде. Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Рәиснең Юлламасын гамәлгә ашыру буенча Комплекслы гамәлләр планында кече технологик компанияләр тарафыннан дәүләт ярдәме чараларын алуда булышлык күрсәтү гамәлләре каралган.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып һәм Федераль закон белән бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру йөзеннән закон проекты белән, кече технологик компанияләргә карата технологик компанияләр эшчәнлеген кызыксындыруның региональ алымнарын куллану максатларында «кече технологик компанияләр» төшенчәсен кертеп, «Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының җайга салу предметын һәм аның төшенчәләр аппаратын киңәйтү тәкъдим ителә. Шулай ук кече технологик компанияләргә дәүләт ярдәмен гамәлгә ашыру үзенчәлекләрен беркетә торган яңа $18^1$ статьяны кертү тәкъдим ителә.

Закон проекты Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеген кызыксындыруга юнәлдерелгән. Законны кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итмәячәк.

**«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнарны таләп итми.